КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 27 декабрь г.Казань № 1041

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына теркәлгән Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарына беркетелә торган җирле бюджетлар керемнәре чыганаклары исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 1 март, 143 нче; 2013 ел, 24 май, 348 нче; 2014 ел, 31 гыйнвар, 51 нче; 2014 ел, 11 август, 583 нче; 2015 ел, 18 май, 353 нче; 2015 ел, 5 сентябрь, 645 нче; 2016 ел, 26 октябрь, 780 нче; 2017 ел, 14 апрель, 228 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) теркәлгән Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарына беркетелә торган җирле бюджетлар керемнәре чыганаклары исемлегенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

I бүлектә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына беркетелә торган керемнәр чыганаклары:

1) шәһәр округлары ихтыяҗлары өчен дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итәр өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен түләтелгән акча (штрафлар);

2) муниципаль районнар ихтыяҗлары өчен дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итәр өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен түләтелгән акча (штрафлар);

3) авыл җирлекләре ихтыяҗлары өчен дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итәр өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен түләтелгән акча (штрафлар);

4) шәһәр җирлекләре ихтыяҗлары өчен дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итәр өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен түләтелгән акча (штрафлар).»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына беркетелә торган керемнәр чыганаклары:

Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексының 20.25 статьясында каралган административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен түләтелгән акча (штрафлар).»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы Биология ресурслары буенча дәүләт комитетына беркетелә торган керемнәр чыганаклары:

хайваннар дөньясын саклау һәм файдалану турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен түләтелгән акча (штрафлар);

аерым саклана торган табигать территорияләре турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен түләтелгән акча (штрафлар).»;

искәрмәдә «Татарстан Республикасы хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин